ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

01 ноябрь 2025 ел

**КАРАР**

№ 8987

2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 27 мартындагы 1541 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2026 елга расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны кушымтада каралганча;

2) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,85 күләмендә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында каралган норматив чыгымнарга туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 1 ноябрендәге
8987 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү
мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүгә
норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (елына бер укучыга сум) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | сигез еллык укыту срогы | иртә һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | 99 826 | 95 524 | 96 798 | 111 416 | 115 995 | 150 794 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | 0 | 49 900 | 42 477 | 39 295 | 43 367 | 99 300 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | 0 | 0 | 97 308 | 79 435 | 84 263 | 342 950 |
| Гомуми эстетика сәнгате | шәһәр җирлеге | 0 | 0 | 43 534 | 0 | 0 | 0 |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | 0 | 0 | 101 217 | 97 465 | 100 551 | 165 858 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 156 530 | 0 | 151 191 | 0 | 0 | 263 997 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 77 614 | 70 087 | 72 585 | 72 557 | 76 069 | 107 794 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева